КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 10 ноябрь г.Казань № б-2450

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Йогышлы авыруларны профилактикалау буенча санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СанПиН 3.3686-21 нче санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган «Йогышлы авыруларны профилактикалау буенча санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СанПиН 3.3686-21 нче санитария кагыйдәләренең һәм нормаларының «Сальмонеллезны профилактикалау» дигән XXVI бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы халкының санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында, бу боерыкка теркәлгән 2022 – 2027 елларга Татарстан Республикасы территориясендә сальмонеллез инфекциясен профилактикалау чараларының комплексны планын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 10 ноябрь, б-2450 нче
боерыгы белән расланды

2022 – 2027 елларга Татарстан Республикасы территориясендә
сальмонеллез инфекциясен профилактикалау чараларының комплекслы планы

| Т/с | Чараның исеме | Башкару срогы | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Оештыру чаралары | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә сальмонеллезларны профилактикалау мәсьәләләре буенча уртак эш киңәшмәләрен үткәрү, сальмонеллез таралу интенсивлыгын киметү буенча чараларны көчәйтү мәсьәләләрен башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары каравына чыгару | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе *(килешү буенча) |
| 1.2. | Сальмонеллезлар буенча эпидемиологик, эпизоотик вәзгыять торышы турында, терлекчелек һәм кошчылык продуктларын лабораториядә тикшерү нәтиҗәләре турында системалы рәвештә мәгълүмат алмашуны тәэмин итү | квартал саен | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 16 нчы биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | дәүләт бюджет учреждениесе |
| 1.3. | Лабораторияләрнең сальмонеллез белән авыручы кешеләр һәм хайваннардан алынган материалларны лабораториядә тикшерүгә даими әзер булуын тәэмин итү. Кискен эчәк инфекцияләре белән авыручылардан алынган материалны тикшерү (шул исәптән лаборатория диагностикасының заманча ысулларын кулланып) өчен кирәкле диагностик тест-системалары запасын булдыру | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләре, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2. Ветеринария-санитария чаралары | | | |
| 2.1. | Сальмонеллезны мониторинглау буенча референс-үзәк («Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Эпидемиология үзәк фәнни тикшеренү институты» федераль дәүләт фән учреждениесе) белән, шул исәптән җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү һәм терлекчелек фермаларында, шулай ук кошчылык хуҗалыкларында авырулар санын тикшергәндә, территориядә хәл катлауланганда, Татарстан Республикасы территориясендә сальмонеллаларның яңа серотиплары барлыкка килү һәм таралу сәбәпләре билгеләнгәндә хезмәттәшлек итүне тәэмин итү | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.2. | Сальмонеллезларны профилактикалау һәм дәвалау өчен төп препаратлар запасын, шул исәптән терлекләр сальмонеллезына каршы вакциналар булуын тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.3. | Лабораторияләрнең сальмонеллага лаборатор тикшеренүләрен (шул исәптән диагностиканың иммунохимик һәм молекуляр-генетик ысулларын кулланып) үткәрүгә әзер булуын тәэмин итү | ел дәвамында | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.4. | «Ябык типтагы предприятиеләр» режимында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары эшен тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.5. | Предприятие эшенең барлык этапларында дезинфекция | ел дәвамында | Татарстан Республикасында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | режимын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итү, санитария законнары нигезендә дезинсекция, дератизация чараларын үткәрү. Дезинфекция чараларының даими запасы булуын тәэмин итү (хәл катлауланган очракка резерв фонды) | | терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.6. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе рөхсәте белән инкубация йомыркаларын сатып алу һәм сальмонеллез буенча имин булган хуҗалыклардан (илләрдән) ата-ана терлеген комплектлау | ел дәвамында | Татарстан Республикасында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.7. | Ветеринария законнары нигезендә ата-ана терлегеннән яшь терлек һәм тәүлеклек чебешләр кергәндә аларны карантинда тоту (шул исәптән сальмонеллезга бактериологик тикшерү үткәрү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү, терлекчелек һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2.8. | Кош абзарларын файдаланганда технологик ял иттерү вакытларын үтәү, кош-кортларны утырту алдыннан кош абзарларын әзерләү (юу, агарту, сыйфатын лаборатория контролендә тотып дезинфекцияләү) | даими | Татарстан Республикасында кошчылык предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.9. | Зәгыйфь һәм продуктив булмаган кош-кортларны бракка чыгару. Үлгән кош-корларны һәм яшь авыл хуҗалыгы хайваннарын үз вакытында җыю, утилизациягә җибәрү | даими | Татарстан Республикасында кошчылык һәм терлекчелек предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.10. | Сальмонеллезга эпизоотологик һәм иммунологик мониторинг үткәрүне тәэмин итү, Татарстан Республикасы хуҗалыкларының сальмонеллез буенча имин булмаган хуҗалыкларыннан сальмонеллез кузгаткычын аерым изолятларын аерып алу | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.11. | Ата-ана терлегенең яшь ремонт терлегенә сальмонеллезга каршы вакцинация ясау | иммунизация схемасы нигезендә эпизоотик хәл буенча | Татарстан Республикасында кошчылык, җәнлек үрчетү, дуңгыз үрчетү һәм терлекчелек хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.12. | Расланган график нигезендә сальмонеллаларның циркуляциясенә мониторинг үткәрү өчен төрле яшьтәге кош-кортлардан, дуңгызлардан, мөгезле эре һәм вак терлекләрдән алынган биоматериалны сайлап алуны һәм алып баруны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кошчылык һәм терлекчелек предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.13. | Катнаш азык һәм чималның һәр партиясенә бактериологик мониторинг үткәрүне гамәлгә ашыру | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.14. | Кош-кортларның баш санын даими карауны, сальмонеллезга кош-кортның серологик мониторингын, кергә торган азыкларның сыйфатын лабораториядә контрольдә тотуны тәэмин итү, кош-кортның үлүенә эксперт бәяләвен бирү һәм аны анализлау. Үлгән кош-кортны патологоанатомик ярып карау, шик булганда сальмонеллезга бактериологик тикшерү үткәрүгә материал җибәрү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.15. | Кош-кортны суюга тапшырганга кадәр 5 – 7 көн кала 4 – 6 баш тере бройлерларны сальмонелл йөртүгә тикшерү | ел дәвамында | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), район ветеринария лабораторияләре (килешү буенча) |
| 2.16. | Беренче яралган атнада инкубация калдыкларына һәм үлгән чебешләргә лаборатория мониторингын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кошчылык һәм терлекчелек хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.17. | Инкубаторларда, кош абзарларында, инкубация һәм ашханә йомыркасында дезинфекция сыйфатына лаборатория контролен үткәрү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары, кошчылык хуҗалыкларының җитештерү лабораторияләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.18. | Сальмонеллезга лаборатория бәяләмәсе белән ветеринария буенча иярчен документлар нигезендә чалу өчен тере кош-кортны кабул итүне гамәлгә ашыру | ел дәвамында | үз составында Татарстан Республикасында кош-корт чалу һәм эшкәртү цехы булган кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.19. | Җитештерелә торган кош-корт продукциясе ассортиментына Таможня берлегенең «Азык-төлек продукциясе иминлеге турында» 021/2011 нче техник регламенты таләпләренә туры килү-килмәүгә микробиологик тикшеренү үткәрү | 10 көнгә 1 тапкыр | үз составында Татарстан Республикасында кош-корт чалу һәм эшкәртү цехы булган кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.20. | Җайланмалар, инвентарьлар, таралар, махсус киемнәр, терлек чалу мәйданчыкларын юу һәм дезинфекцияләү сыйфатын лабораториядә контрольдә тоту | айга 2 тапкыр | үз составында Татарстан Республикасында кош-корт чалу һәм эшкәртү цехы булган кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасында кош-корт эшкәртү предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.21. | Терлекчелек, кошчылык комплексларында агызып төшерелә торган суларны биологик чистарту корылмаларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү, зарарсызландыру сыйфатын җитештерү контролендә тоту | ел дәвамында | Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы предприятие-ләре җитәкчеләре (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Респуб-ликасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 2.22. | Татарстан Республикасы базарларында, сәүдә комплексларында ит, сөт һәм башка терлекчелек продуктларына ветеринария-санитария экспертизасын үткәрү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында базарлар, сәүдә комплекслары администрациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2.23. | «Ябык типтагы предприятиеләр» режимында кошчылык хуҗалыклары эшенә, терлекчелек предприятиеләре эшенә законнарда билгеләнгән тәртиптә сальмонел-лезларны профилактикалау өлешендә күзәтчелек итүне тәэмин итү, терлек азыклары җитештерү техноло-гиясенә карата ветеринария-санитария таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту | ел дәвамында | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2.24. | Татарстан Республикасы территориясенә инкубация йомыркасы, тере кош-корт, кош-корт ите, кошчылык продукциясенең барлык төрләре, азыклар һәм азык өстәмәләре, мамык һәм каурый керүне контрольдә тотуны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 2.25. | Кош-корт ите һәм кош-корт продукциясен сата торган | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | базарларда, сәүдә комплексларында, азык-төлек сәнәгате, сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрендә контроль-күзәтчелек чараларын тәэмин итү | | өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 2.26. | Кошчылык предприятиеләрендә сальмонеллаларның яңа серотиплары барлыкка килү сәбәпләрен тикшерүне тәэмин итү. Татарстан Республикасы территориясендә аларның таралуын кисәтү буенча чаралар күрү | барлыкка килгәндә | Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.27. | Сальмонеллез буенча эпизоотик хәл катлауланганда, терлек/кош-корт төрен исәпкә алып, әлеге хуҗалыкны/предприятиене сальмонеллез буенча имин булмаган дип игълан итеп, терлекчелек хуҗалыкларында (предприятиеләрдә), шул исәптән кошчылык хуҗалыкларында законнар белән билгеләнгән тәртиптә эпизоотиягә каршы чикләү чараларын кертү һәм түбәндәгеләрне тыю:<br>көтүләрне комплектлау өчен инкубация йомыркаларын һәм кош-кортларны башка хуҗалыкларга чыгаруны;<br>уңай нәтиҗә биргән кош-кортлар йомыркаларын сәүдә челтәренә чыгаруны;<br>хуҗалык эчендә имин булмаган кош-корт абзарлары йомыркаларын инкубацияләүне.<br>Лаборатория контроле нәтиҗәләрен исәпкә алып, комиссия белән чикләү чараларын гамәлдән чыгару турында карар чыгару | лаборатория мониторингы мәгълүматларын ай саен бәяләү нәтиҗәләре буенча | Татарстан Республикасында кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 2.28. | Авыру хайваннарны һәм бактерия йөртүчеләрне (шул исәптән сальмонеллез учакларында) актив ачыклауны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.29. | Сальмонеллез белән авыручы хайваннарны һәм сальмонелла йөртүчеләрне, шул исәптән алдан профилактик һәм әледән-әле тикшерүләр үткәргәндә ачыкланганнарны тулысынча һәм үз вакытында исәпкә алуны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2.30. | Сальмонеллез чыккан урыннарда беренчел эпизоотиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү, шул исәптән авыру хайваннарны лабораториядә тикшерүне тулысынча һәм үз вакытында башкаруны, очраклар теркәлгәндә, антибиотикка сизгерлекне исәпкә алып, адекват терапия ясауны тәэмин итү | очраклар теркәлгәндә | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2.31. | Җитештерү контроле барышында сальмонеллалар билгеләнү очраклары турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә мәгълүмат бирү | билгеле булган очракта | Татарстан Республикасында азык-төлек сәнәгате, җәмәгать туклануы, сәүдә предприятиеләре, дәвалану һәм профилактика учреждениеләре, мәгариф, савыктыру учреждениеләре, социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре |
| 2.32. | Азык-төлек продуктлары җитештерелә торган предприятиеләрдә ветеринария-санитария нормаларының һәм кагыйдәләренең, шулай ук базарларда терлекчелек һәм кошчылык продуктларын саклау, транспорт белән ташу һәм реализацияләү өчен аларның сальмонеллалар йоктыру һәм алар белән пычрану мөмкинлеген булдырмый торган тиешле шартларның үтәлешенә дәүләт ветеринария күзәтчелеген тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2.33. | Авыл хуҗалыгы хайваннары һәм кош-кортларының зооноз инфекцияләре белән авырулар санын мониторинглауны, терлекчелек һәм кошчылык продуктларын | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | лабораториядә тикшерүләр нәтиҗәләрен һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләре белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү | | |
| 2.34. | Татарстан Республикасы кош-корт эшкәртү предприятиеләрендә шартлы-яраклы кош-корт итен эшкәртү участогы һәм чимал һәм продуктларны саклау өчен суыткычлар булган санитария камералары, автомашиналар, контейнерлар һәм тартмалар өчен дезинфекцияләү-юу пунктлары, цех эчендәге инвентарьне, әзер продуктлар өчен билгеләнгән, кире кайтарыла торган тараны, калдыкларны чыгару тарасын һәм транспортын юу һәм дезинфекцияләү өчен аерым юу бүлекләре, йомырка тарасын дезинфекцияләү участоклары, дезинфекция эремәләрен үзәктән әзерләү өчен аерым бүлмәләр һәм дезинфекция чаралары складлары булуын, санитар тикшереп үткәрү тибында санитария-көнкүреш бүлмәләре булуын, санитар киемне көн саен үзәктән юу өчен билгеләнгән, «чиста» һәм «пычрак» зоналарга аеру агымы саклана торган итеп җиһазландырылган кер юу бүлмәсе булуын тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кош-кортларны эшкәртү предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.35. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә хайваннар арасында зооноз инфекцияләре белән авырулар саны, терлекчелек һәм кошчылык продуктларын лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре турында белешмә бирүне тәэмин итү | квартал саен, аннан соң килә торган айның 30ына кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 3. Санитария-профилактика чаралары | | | |
| 3.1. | Терлекчелек, кошчылык, азык-төлек сәнәгате, җәмәгать туклануы предприятиеләре, сәүдә, балалар белем бирү, | ел дәвамында | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | социаль һәм сәламәтләндерү, медицина оешмаларына карата, санитария законнарын бозуны ачыклаган өчен административ йогынты чаралары күреп, план буенча һәм планнан тыш контроль-күзәтчелек чараларын үз вакытында һәм сыйфатлы үткәрүне тәэмин итү | | буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 3.2. | Эпидемия чыккан урыннар барлыкка килүнең сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен билгеләп һәм сальмонеллез чыккан урыннарда эпидемиягә каршы санитария (профилактика) чараларын оештырып, эпидемиология тикшеренүләрен сыйфатлы итеп үткәрүне тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 3.3. | Татарстан Республикасы халкы арасында, әйләнә-тирә мохит объектларында, азык-төлек продуктларында сальмонеллезлар белән авырулар санын һәм сальмонеллалар циркуляциясен мониторинглау | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 3.4. | Сальмонеллез чыгу урыннарында эпидемиология тикшерүләрен, эпидемиягә каршы үткәрелә торган санитария (профилактикы) чараларын үз вакытында үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итү | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 3.5. | Сальмонеллезлар белән авыру санына оператив һәм ретроспектив анализ ясауны тәэмин итү, авырулар санын фаразлау һәм профилактика чаралары һәм эпидемиягә каршы чараларны анализлау мәгълүматлары нигезендә үз вакытында төзәтмәләр кертү | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 3.6. | Мәгариф, сәламәтләндерү, дәвалау-профилактика учреждениеләре һәм халыкны социаль яклау учреждениеләренең пищеблокларында кош-корт итен (суытылган иттән тыш), сөяге иттән механик аерылган кош-корт итен һәм кош-корт итеннән эшләнгән коллагенлы чималны кабул итүне һәм куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында азык-төлек сәнәгате предприятиеләре, җәмәгать туклануы предприятиеләре, медицина, мәгариф, савыктыру учреждениеләре, социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.7. | Азык-төлек сәнәгате предприятиеләрендә кош-корт итен һәм йомыркаларны кулланганда технологик процессның һәм санитария-дезинфекция режимының үтәлешен тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында азык-төлек сәнәгате предприятиеләре, җәмәгать туклануы предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.8. | Азык-төлек продуктларының һәр төренә норматив һәм техник документация таләпләре нигезендә, шулай ук тиз бозыла торган йөкләрне төрле транспорт төрләре белән ташу кагыйдәләре нигезендә кош-корт продуктларын транспортлау шартлары (температура, дымлылык) үтәлешен тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасында кош-корт эшкәртү предприятиеләре, күпләп һәм ваклап сату предприятиеләре, җәмәгать туклануы предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.9. | Җәмәгать туклануы оешмаларында, шул исәптән мәгариф, савыктыру, дәвалау-профилактика учреждениеләре, халыкны социаль яклау учреждениеләренең пищеблокларында кош-корт итен юу өчен аерым юу ванналары, кисү-турау өчен маркаланган инвентарь һәм җиһаз, шул исәптән кош-корт ите өчен махсус билгеләнгән суыту җиһазы булуын, технологик барыш агымы үтәлешен тәэмин итү | ел дәвамында | теләсә кайсы милек рәвешендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.10. | Массакүләм мәдәни һәм спорт чараларын (шәһәр көннәре, Сабантуй һ.б.) үткәрү чорында туклануны оештырганда эпидемиологик яктан куркыныч ризыклар сатуны контрольдә тотуны тәэмин итү, кош-корт итеннән шашлык ясауны һәм сатуны тыю | үткәрү чорында | Татарстан Республикасында җәмәгать туклануы, сәүдә, азык-төлек сәнәгате предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 3.11. | Предприятиеләр хезмәткәрләренең алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүен 100 процент үтүен, алга таба аттестация үтеп, гигиена буенча белем алуын, профилактика прививкаларының илкүләм календаре һәм эпидемия күрсәткечләре буенча прививкалар календаре кысаларында профилактика прививкалары турында белешмәләре булуын тәэмин итү | ел дәвамында | теләсә кайсы милек рәвешендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.12. | Азык-төлек предприятиеләренә һәм азык-төлек продукциясе сатыла торган сәүдә объектларына, сөт | ел дәвамында | теләсә кайсы милек рәвешендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | кухняларына, сөт фермаларына, сөт заводларына һәм эшкәртү заводларына, шулай ук турыдан-туры туклану продуктларын эшкәртү, саклау, транспортлау һәм әзерләнгән ризыкны бирү белән шөгыльләнә торган предприятиеләргә, балалар һәм медицина оешмаларына, суүткәрү корылмаларын эксплуатацияләүне, эчәргә яраклы суны китереп бирү һәм саклауны гамәлгә ашыра торган оешмаларга хезмәткәрләрне сальмонеллезларны кузгалтучылар булу-булмауга лаборатория тикшерүе нәтиҗәләре белән эшкә алуны тәэмин итү | | |
| 3.13. | Оештырылган коллективларда, шул исәптән балаларның җәйге ялы һәм аларны сәламәтләндерү учреждениеләрендә балаларның куркынычсыз туклануын тәэмин итү буенча чаралар күрү, азык-төлек продуктларын транспортлау, саклау, әзерләү шартларын, шулай ук йомыркаларны зарарсызландыру режимын катгый үтүне тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| 3.14. | Азык-төлек предприятиеләре, җәмәгать туклануы предприятиеләре һәм сәүдә объектлары хезмәткәрләренең алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен, тикшеренүләрне үтүе һәм гигиена буенча белем алуы дөрес һәм тулы күләмдә булуын, профилактика прививкаларының илкүләм календаре һәм эпидемия күрсәткечләре буенча прививкалар календаре кысаларында профилактика прививкалары турында белешмәсе булуын контрольдә тотуны көчәйтү | контроль-күзәтчелек чараларын үткәргәндә ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 3.15. | Шәһәр яны җәйге савыктыру учреждениеләренең эшен: туклану, су белән тәэмин итү, яшәү куркынычсызлыгын контрольдә тотуны тәэмин итү | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.16. | Азык-төлек чималын һәм азык-төлек продуктларын җитештерү, саклау, транспортлау һәм реализацияләү белән шөгыльләнә торган объектларның һәм җәмәгать туклануы буенча хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы объектларның санитария нормаларына һәм кагыйдәләренә катгый туры китерү | ел дәвамында | теләсә кайсы милек рәвешендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.17. | Авыру кош-корт һәм сыйфаты буенча шикле чимал керү яки кош-корт продуктларын җитештергән вакытта аларны ачыклау очраклары турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган территориаль бүлекләргә үз вакытында хәбәр итү | кергәндә яки яңартканда кичектергесез | Татарстан Республикасында кошчылык фабрикалары һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.18. | Халыкка, җирле үзидарә органнарына, дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашырырга вәкаләтле органнарга халыкның санитария-эпидемиология иминлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлләре, җитештерү туктатылу, технологик процесслар бозылу турында үз вакытында хәбәр итү | эпидемиологик хәл катлауланганда кичектермәстән | Татарстан Республикасында кошчылык фабрикалары һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.19. | Санитария-эпидемиология таләпләре бозылу билгеләнгәндә ачыкланган бозуларны бетерүгә һәм аларның барлыкка килүен булдымауга юнәлдерелгән чаралар кабул итү Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнарга санитария-эпидемиология таләпләрен бозуларны бетерү буенча күрелгән чаралар, җитештерү контроле нәтиҗәләре турында хәбәр итү | ачыкланганда кичектермәстән | Татарстан Республикасында кошчылык фабрикалары һәм кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.20. | Массакүләм чаралар үткәргәндә продукция белән тәэмин итеп торучы кош-корт эшкәртү предприятиеләре персоналының кискен эчәк инфекцияләрен, корсак тифын, ротовируслар һәм норовируслар кузгалтучы- | чара башланганга кадәр ике атна кала | Татарстан Республикасында массакүләм чаралар үткәргәндә продукция белән тәэмин итеп торучы кош-корт эшкәртү предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | ларны йөртүенә чираттан тыш тикшерү үткәрүне тәэмин итү | .<br>. | |
| 3.21. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына ачыкланган санитария законнарын бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәләрнең һәм административ хокук бозуны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү турында күрсәтмәләрнең индивидуаль эшмәкәрләр һәм юридик затлар тарафыннан берничә тапкыр үтәлмәвенең һәр очрагы турында мәгълүмат бирү | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 3.22. | Филиаллар лабораторияләре тарафыннан әйләнә-тирә мохит объектларыннан бүлеп чыгарыла торган сальмонеллалар штаммнарын идентификацияләүне раслауны тәэмин итү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасында (Татарстан) буенча Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 4. Дәвалау-профилактика (эпидемиягә каршы) чаралары | | | |
| 4.1. | Авыруларны һәм бактерия йөртүчеләрне актив ачыклауны тәэмин итү, шул исәптән:<br>сальмонеллезлар чыккан урыннарда;<br>кайбер һөнәрләр, производстволар һәм оешмалар (декретлаштырылган төркем) хезмәткәрләренең беренчел һәм даими медицина тикшерүләрен үткәргәндә;<br>норматив документлар нигезендә затлар категорияләрен тикшергәндә | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 4.2. | комплексны тикшеренүләр ысулларын кулланып, эчәк инфекцияләрен иртә ачыклау һәм диагностикалауны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.3. | Эпидемиология үзенчәлекләрен, клиниканы, сезонлыкны исәпкә алып, сальмонеллаларны, шул исәптән штаммаларны, ДНКны, антигеннарны, антителаларны | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | индикацияләргә һәм идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган диагностиканың бактериологик, вирусологик, серологик һәм башка ысулларын кулланып, тулы этиологик расшифровкасын бирү максаты белән барлык кискен эчәк инфекцияләре белән авыручыларны тикшерүне тәэмин итү | | |
| 4.4. | Барлыкка китерүче таралу юлларын һәм факторларын ачыклау максатларында, сальмонеллезлар белән төркемләп, күпләп авырганда таралу факторы буларак шиккә алынган азык-төлек продуктлары, блюдолары калдыкларын лабораториядә тикшерү, азык-төлек чималын, йомыркалар, җиһаз, куллар, инвентарьларны, тышкы мохитнең башка объектларын юган суларны тикшерү | күрсәтмә нигезендә төркем белән, кинәт арткан сальмонеллез-лар белән авырулар саны барлыкка килгәндә | «Татарстан Республикасында (Татарстан) буенча Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 4.5. | Сальмонеллез белән авыручыларны һәм сальмонеллаларны йөртүчеләрне, шул исәптән алдан профилактик һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үткәргәндә ачыкланганнарны тулысынча һәм үз вакытында исәпкә алуны тәэмин итү (ашыгыч игъланнар бирү) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.6. | Сальмонеллез чыккан урыннарда беренчел эпидемиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү, шул исәптән авыруларны һәм контактта булучыларны лабораториядә тикшерүне тулысынча һәм үз вакытында башкаруны, очраклар теркәлгәндә, антибиотикограмманы исәпкә алып, адекват терапия ясауны тәэмин итү | очраклар теркәлгәндә | Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.7. | Ике яшькә кадәрге контактта булган балалар һәм өлкән яшьтәге затлар арасында сальмонеллез белән авырулар саны арту теркәлгәндә бактериофаг белән ашыгыч профилактика үткәрүне тәэмин итү | очраклар теркәлгәндә | Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.8. | Татарстан Республикасы медицина оешмаларында хастаханә эчендә сальмонеллез очракларының барлыкка килүен һәм таралуын кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар | ел дәвамында | Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | комплексын үткәрүне тәэмин итү | | |
| 4.9. | Сальмонеллезлар белән авыру саны кинәт артканда госпиталь базасының дәвалау-диагностика чараларын гамәлгә ашыруга әзерлеген тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.10. | Татарстан Республикасы медицина оешмаларының йогышлы авырулар стационарларында (йогышлы авырулар бүлекләрендә) эпидемиологик хәл катлауланганда авыруларны, шул исәптән сальмонеллез инфекциясе булуы мөмкин булган клиникалы авыруларны хастаханәгә салу өчен өстәмә бүлекләр (койкалар) булдыру планнарына төзәтмәләр кертүне тәэмин итү | ел саен | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 4.11. | Сальмонеллезлар белән авыру саны төркемләп һәм күпләп барлыкка килгәндә оператив рәвештә чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларын дәвалау һәм медицина иммунобиологик препаратларының кимеми торган запасы белән тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 5. Мәгълүмат-белем бирү эше | | | |
| 5.1. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына, халыкка Татарстан Республикасы территориясендә, шул исәптән кошчылык хуҗалыкларында, сальмонеллезлар һәм эпизоотик хәлнең авыру дәрәҗәсе турында мәгълүмат бирү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 5.2. | Ветеринария хезмәтенең профильле белгечләре киңәшмәләрендә, Татарстан Республикасының кошчылык һәм кош эшкәртү предприятиеләре белгечләре белән киңәшмәләрдә сальмонеллезларны профилактикалау мәсьәләләрен яктырту | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 5.3. | Дәвалау челтәренең, Кеше хокукларын яклау һәм кеше | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | иминлеген саклау күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең профильле белгечләре киңәшмәләрендә сальмонеллезларны профилактикалау мәсьәләләрен яктырту | | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 5.4. | Җәмәгать туклануы, ваклап сату, азык-төлек сәнәгате предприятиеләре персоналы, балалар белем бирү һәм сәламәтләндерү учреждениеләре персоналы, башка предприятиеләр һәм учреждениеләр, теләсә нинди милек рәвешендәге, эшләре азык-төлек продуктларын җитештерү, әзерләү, саклау, ташу һәм сату, су белән тәэмин итү процессына бәйле булган башка предприятиеләр һәм учреждениеләр персоналы өчен семинарларда, гигиена курсларында сальмонеллез-ларны профилактикалау мәсьәләләрен яктырту | ел дәвамында | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 5.5. | Массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән интернет-ресурслардан файдаланып, сальмонеллез-ларны профилактикалау мәсьәләләрен киң яктыртуны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 5.6. | Халык белән сальмонеллезларны профилактикалау мәсьәләләре буенча актив ветеринария-санитария агарту эшен тәэмин итү (әңгәмәләр, лекцияләр һ.б.) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, «Казан шәһәренең Дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 5.7. | Халык белән сальмонеллезларны профилактикалау мәсьәләләре буенча актив санитария-агарту эшен тәэмин итү (әңгәмәләр, лекцияләр, санитария бюллетеньнәре, сәламәтлек мәктәпләре һ.б.) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | буенча идарәсе (килешү буенча) |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

татар текстында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе үзгәрешсез кала;

татар текстында «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Эпидемиология үзәк фәнни тикшеренү институты» федераль дәүләт фән учреждениесе үзгәрешсез кала.